ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 199

Кайбыч муниципаль районында
2019-2020 еллар ягу сезоны тәмамлану һәм
2020-2021 еллар көзге-кышкы ягу чорына әзерләнү турында

РФ Хөкүмәтенең «Милекче һәм кулланучыларга күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары нигезендә һәм торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләрен, Цельсий буенча 8 градустан югарырак уртача тәүлеклек тышкы һава температурасы артык урнашу сәбәпле, ягулык-энергетик комплекс һәм социаль мәдәни көнкүреш объектларын 2019-2020 еллар көзге-кышкы ягу чорына вакытында һәм сыйфатлы әзерләү максатында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРДЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы бюджет өлкәсе учреждениеләренә тәкъдим итәргә:

1.1. 2019 - 2020 елның җылыту сезонын, тышкы яктагы газ казаннары булган учреждениеләрдән тыш, 2020 елның 1 апреленнән социаль билгеләнештәге объектларга (мәдәният, мәгариф, мәктәпкәчә учреждениеләргә) тәмамларга.

1.2. Ягулык сезонын ягулык-саклаучы режимнан файдаланып дәвам итәргә.

1.3. Җәйге чорда кайнар су бирүне тәэмин итәргә.

1.4. Пар казаннары бинасында, үзәк җылылык пунктларында , җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә һәм эчке инженер системаларында объектларны көзге-кышкы ягу чорына әзерләү чаралары нигезендә ремонтлау һәм профилактика эшләрен башларга.

2. Объектларны 2020 - 2021 елларның көзге-кышкы чорына әзерләүне 2020 елның 15 сентябренә төгәлләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров